Эшне үтәү буенча кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 12 биремне үз эченә ала (А1-А12), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыксса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 2 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 3-4 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез !

3 вариант

1 өлеш (А)

Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А12) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.

А1. Калын сузык авазлардан торган сүзләр рәтен билгеләгез.

1. күлмәк, китап, күз, кишер
2. ваза, роза, балык, егет
3. сөлге, көймә, мәче, өрәңге
4. каен, зал, арыслан, кыяр

А2. Яңгырау булмаган авазны табыгыз.

1. [х]
2. [з]
3. [р]
4. [л]

А3. Борын тартыкларын билгеләгез.

1. [ж], [w], [h]
2. [м], [н], [ң]
3. [д], [ж], [ж]
4. [б], [в], [з]

А4. Кайсы рәттәге сүзләрдә ъ хәрефе языла?

1. кул...яулык, ар...як, кул...югыч
2. биш...еллык, тигез...яклы, гам...сез
3. көн...як, төн...як, пул...с
4. бер...юлы, бер...яклы, бер...еллык

А5. Күплек сандагы исемнәрдән торган рәтне табыгыз.

1. үләннәр, куяннар, килгәннәр;
2. керпеләр, аюлар, еланнар;
3. укыйлар, язалар, саныйлар;
4. матурлар, зурлар, акыллылар.

А6. **Тамырдаш сүзләрдән торган рәтне табыгыз.**

1. урак, урман, урды
2. көйлә, көйле, көйсез
3. сөлге, сөрт, сөртенде
4. карга, карлы, карсыз

А7. *Үги ана яфрагы* **сүзенең ясалышын билгеләгез.**

1. ясалма;
2. тезмә;
3. парлы;
4. кушма.

А8. Бирелгән мәкальдә күп нокталар урынына кайсы кушымчалар куела?

Тел... барның ил... бар.

1. – ем
2. – ең
3. – е
4. – егез

А9. **Бирелгән сүзләр арасыннан сыйфатларны табыгыз.**

1. яши, сулана, бозлана
2. яшьлек, су, боз
3. ямьле, сулы, бозлы
4. яшәү, сулау, бозлану

А10. **Җөмләнең ия турында хәбәр итә торган баш кисәге ничек дип атала?**

1. аергыч
2. тәмамлык
3. хәбәр
4. хәл

А11. Сыйфат кайсы сорауларга җавап бирә?

1. нишли? нишләде?;

2. кем? нәрсә?;
3. нинди? кайсы?;
4. ничә? ничәнче?.

А12. Тәртип саны нинди сорауга җавап бирә?

1. ничәнче?
2. ничә?
3. никадәр?
4. ничәләп?

2 өлеш (В)

Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.

1) Бүген әниемнең туган көне. (2)Иртән торып, аның йокы бүлмәсенә чәчәкләр куйдым. (3)Аннары өстәлгә ап-ак ашъяулык яптым.(4) Өстәл өстенә чәкчәк, җиләк-җимеш тездем. (5)Менә әни дә уянды.(6)Ул шатлык, сөенеч күзләре белән карады.(7) Кадерле әниебезне туган көне белән котладык.(8)Аңа олы бәхет теләдек, аны авырлыклар читләтеп үтсен.

В1. 3 нче җөмләдәге сыйфатның антонимын языгыз.

В2. 3 нче җөмләдәге кушма сүзне табып языгыз.

В3. 6 нчы җөмләдән алмашлыкны табып языгыз.

В4. 8 нче җөмләдән юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзләрне язып алыгыз.

В5. 5 нче җөмләдәге нечкә сузыклардан торган исемне юнәлеш килешенә куеп языгыз.

В6. Текстан [w] авазы булган сүзне язып алыгыз.